| | |
|---|---|
| **СОВЕТ**<br>**Девятернинского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Девәтернә авыл җирлеге**<br>**СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

07.02.2025 Девәтернә авылы № 56-1

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» Әгерҗе муниципаль районы Девәтернә авыл җирлеге советының 26.11.2019 елның 54-1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 13 июлендәге 177-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Девәтернә авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» Әгерҗе муниципаль районы Девәтернә авыл җирлеге советының 26.11.2019 елның 54-1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 39 статьяның 1 пунктындагы 13 абзацында «паспортлар тапшырыла» сүзләрен «паспортлар (паспорт проектлары) тапшырыла» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 42 статьяның 3 пунктындагы 14 абзацын төшереп калдырырга;

1.3. 42 статьяның 3 пунктына түбәндәге эчтәлекле яңа уникенче абзац өстәргә:

«бюджет ассигнованиеләре ашыгыч гуманитар җавап бирү, гуманитар ярдәм йөкләрен китерү, халыкны эвакуацияләү, гадәттән тыш хәлләрне бетерү чараларын финанс белән тәэмин итүгә яңадан бүленгән очракта.»;

Уникенче - унөченче абзацлар тиешенчә унөченче - ундүртенче абзацлар булып санала.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль

берәмлекләре порталы составында урнаштырырга (https://agryz.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Девәтернә авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендында халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы Э.Э. Ганиев